# УКЫТУЧЫЛАР ДИНАСТИЯСЕ

# ГЫЙЗЗӘТУЛЛИННАР



## Шәһит Гыйззәтуллин

Гыйззәтуллиннар нәселенең укытучылар династиясе Шәһит Гыйззәтуллиннан башланып китә.

Шәһит Гыйззәтуллин 1925 елны Иске Роман авылында туа. 15 яшьлек егетне Паратск (хәзерге Яшел Үзән) шәһәрендәге ФЗӨ мәктәбенә укырга җибәрәләр. Сугыш башлангач, Ижевскида сугыш кораллары ясаучы цехта эшли.


Кем булып кына эшләми ул: тракторчы, шофер, эретеп ябыштыручы, укытучы, авыл советы рәисе.

1963нче елда Чистайда укытучылар өчен бер еллык курсларны тәмамлап, Иске Роман сигезьеллык мәктәбендә физкультура укытучысы булып эшли. Үзенең өч баласының да укытучылар булуын тели ул. Әти кешенең теләге тормышка аша: уллары Рәшит, Рәис, кызы Әлфия- Алабуга дәүләт педагогия институтын тәмамлап, физика, математика укытучысы булып эшли башлыйлар.



# УКЫТУЧЫЛАР ДИНАСТИЯСЕ

## ГЫЙЗЗӘТУЛЛИННАР



**Рәшит Шәһит улы Гыйззәтуллин** мәктәптә укыганда ук техник фәннәргә тартылган егет 1974 нче елда Алабуга педагогия институтының физика-математика факультетына укырга керә. Кулына диплом алгач, ул педагогик эшчәнлеген Яңа Чишмә районы Чаллы башы сигезьеллык мәктәбендә физика укытучысы, директор урынбасары булып эшли башлый. Соңрак ул Лебедка, Исләй, Иске Роман мәктәпләрендә 20 ел директор була.



1986 нчы елда Иске Роман авылында яңа мәктәп бинасы төзелә башлый. Рәшит Шәһит улы яңа мәктәпне сафка бастыру, аның матди-техник базасын яңарту өчен бик күп тырышлык куя. «Хезмәтемнең төп күрсәткече – укучыларымның минем профессияне сайлавы», - ди ул горурланып. Рәшит Гыйззәтуллин – Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыкларының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән.

# УКЫТУЧЫЛАР ДИНАСТИЯСЕ

УКЫТУЧЫЛАР
һӘМ ОСТАЗЛАР
ЕЛЫ
2023
ГОД
ПЕДАГОГА
И НАСТАВНИКА

## ГЫЙЗЗӘТУЛЛИННАР



**Розалия Рамазанова (Гыйззәтуллина) – Рәшит Гыйззәтуллинның тормыш иптәше.**

1979 нчы елны Арча педагогия училищесын тәмамлый. Яшь кадрны Чистай районы Ислэй авылына эшкә билгелиләр. 5 ел Ислэй сигезьеллык мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта. Күрше Иске Роман авылы егетенә кияүгә чыккач, шул авылда 35 ел балаларга белем һәм тәрбия бирә, озак еллар укыту эшләре буенча директор урынбасары булып эшли.

Розалия Гыйззәтуллина – 20 елга якын районда, республикада татар теле һәм әдәбияты буенча эксперт булып торды. РСФСРның халык мәгарифе отличнигы, Россия Федерациясе Халык мәгарифе почетлы хезмәткәре билгесенә ия.



**Гөлназ Рәшит кызы Гыйззәтуллина** әтисенең юлын сайлап, мәктәпне тәмамлагач, Татар Дәүләт Гуманитар Педагогик Университетының физика факультетына укырга керә. Аны тәмамлагач, шул ук уку йортында методист, Казан шәһәренең Приволжский районында ИМЦда, КФУда укыту-методик эш буенча специалист булып эшли. Чистай шәһәренең 5 нче, 10 нчы мәктәпләрендә физика, математика, информатика укытты.

# УКЫТУЧЫЛАР ДИНАСТИЯСЕ

## ГЫЙЗЗӘТУЛЛИННАР

УКЫТУЧЫЛАР
ҺӘМ ОСТАЗЛАР
ЕЛЫ
2023
ГОД
ПЕДАГОГА
И НАСТАВНИКА



**Рәис Шәһит улы Гыйззәтуллин** 1985 нче елны хатыны Резидә белән Яуширмә урта мәктәбенә эшкә билгеләнәләр. Бер елдан соң алар Татар Сарсазы авылында төпләнәләр. Бу авылда яңа мәктәпкә Рәис Шәһитовичны  директор итеп билгелиләр. Яңа мәктәпнең материаль- техник базасын булдыруга бик зур өлеш кертә, бу җаваплы постта ул чирек гасырга якын эшли.



**Резидә Гыйззәтуллина** Яуширмә, Татар Сарсазы авылларында, Чистай, Казан  шәһәрләрендә  физика, математика, информатика фәннәреннән белем бирде, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булды.

# УКЫТУЧЫЛАР ДИНАСТИЯСЕ

УКЫТУЧЫЛАРҺӘМ ОСТАЗЛАР ЕЛЫ 2023 ГОД ПЕДАГОГА И НАСТАВНИКА

## ГЫЙЗЗӘТУЛЛИННАР



Из поколения в поколение как эстафета передается профессия учителя. Они преподавали и преподают разные предметы, но их объединяет профессионализм, стремление к творчеству, любовь к детям.

Буыннан буынга Гыйззәтуллиннар укытучы һөнәренең бөек әләмен эстафета итеп тапшырган. Алар төрле фәнне укытканнар һәм укыталар да, ләкин аларны професссиональлек, иҗатка омтылыш һәм бар йөрәген балаларга бирү сыйфатлары берләштерә.

